**Галләмов Филүс Гатиф улы,**
*филол. фәннәре докторы,*
*татар филологиясе кафедрасы профессоры,*
*КФУның Алабуга институты*
*Алабуга шәһәре, Татарстан, Россия*
*e-mail: gfilus@yandex.ru*

УДК 811.512.145'367

# ГОМУМИ МӘГЪНӘЛЕ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ТИҢДӘШ КИСӘКЛӘР БЕЛӘН АНЫКЛАНУЫ

# УТОЧНЕНИЕ ЕДИНИЦ С ОБЩИМ ЗНАЧЕНИЕМ ПОСРЕДСТВОМ ОДНОРОДНЫХ ЧЛЕНОВ

# RECTIFICATION OF UNITS WITH TOTAL VALUE BY HOMOGENEOUS TERMS

**Аннотация.** В статье рассматриваются обобщающие слова и словосочетания с однородными членами предложения. Кроме определительных и отрицательных местоимений обобщающие слова выражаются и указательными, и личными, и неопределенными, и другими местоимениями, а также различными именными словосочетаниями. В отличие от традиционной точки зрения в статье определяется синтаксическая функция между однородными членами и обобщающими единицами как уточнительное отношение.

**Ключевые слова:** однородные члены, обобщающие слова, обобщающие словосочетания, уточнения.

**Abstract.** This paper presents general words and word-groups with homogeneous parts of a sentence. Apart from defining and negative pronouns, general words are expressed in demonstrative, subject, indefinite and etc. pronouns and noun phrases. Unlike the established view the paper presents the syntactic function between homogeneous parts of a sentence and general words as a limiting relation.

**Keywords:** homogeneous parts of a sentence, general words, noun phrases.

Татар синтаксисында яшәп килүче «тиндәш кисәкләр нинди җөмлә кисәге булса, гомумиләштерүче сүзләр дә шул ук җөмлә кисәге функциясен башкара» дигән фикер [6, б.490; 3, б.83; 5, б.130–136; 4, б.151–160] бик үк дөреслеккә туры килеп бетми. Бу рус һәм башка телләр синтаксисында да шулай карала. Әлеге ялгышлык гомумиләштерүче сүзләр белән тиңдәш кисәкләрнең барысын бер кисәккә каратудан килеп чыга. Тиңдәш кисәкләр иң беренче чиратта гомумиләштерүче сүзгә, аннан соң гына ул буйсынган сүзгә иярә. Гомумиләштерүче сүзләр белән тиңдәш кисәкләр арасында тезүле бәйләнеш түгел, ә ияртүле (аныклаулы яки төгәлләүле мөнәсәбәт) була. Бәйләүче чаралары да санау интонациясе түгел, ә аныклау интонациясе. Аннан соң алар мәгънә ягыннан да бертигез түгел. Гомуми мәгънәле сүз тиңдәш кисәкләрнең мәгънә суммасына тигез була. Шунлыктан алар тигез хокуклы җөмлә кисәкләре түгел һәм бер синтаксик вазифа башкара алмыйлар. Моны гомумиләштерүче сүзләрнең җөмләдәге урыннарына бәйләп аңлатырга кирәк.

Биредә без гомумиләштерүче сүзләрнең тиңдәш кисәкләрдән алда урнашу очрагын гына карап, аныклагычлар белән чагыштырып, бу кисәкләрнең шул ук аныклагыч һәм аныкланмыш кисәкләр булуын исбатлауны максат итеп куйдык. Гомуми мәгънәле сүз белән тиңдәш кисәкләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтен, интонация үзенчәлеген, грамматик яктан ярашуларын исәпкә алып, алар арасында аныклаулы мөнәсәбәт булуы ачыклана. «Гомумиләштерүче сүз аныкланмыш, ә тиңдәш кисәкләр аныклагыч функциясен башкаралар» [2, б. 96]. Мәгълүм булганча, гомуми мәгънәле аныкланмыш җөмләнең теләсә нинди кисәге вазифасын үти: а) ия: Әйтергә генә ансат, аларның икесен бергә бәйли торган ничаклы уртак дөнья бар бит: тирләп-пешеп бозау куулар, су юлындагы язулар, Гөлҗиһан сабыны, зәңгәр кашлы йөзек, әни агачы, тагын-тагын күпме дөнья, күпме истәлекләр! (Ф.Хөсни); ә) хәбәр: Колхозның бөтен аты тиргә батып кырда эшли: сөрәләр, тырмалыйлар (М.Мәһдиев); б) аергыч: Меңәрләгән-меңәрләгән аяклы мал: сыер, сарык, куй көтүләре уза (М.Әмир);

Бу җыелма күплекне белдерүче сүзләр алдыннан гомумиләштерүне белдерүче билгеләү алмашлыклары килергә мөмкин. Бу очракта гомумиләштерүче сүз булып килгән алмашлыклы исем сүзтезмәне икесен бер җөмлә кисәге итеп алырга кирәк: а) ия: Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы: хатын-кызы, баласы-чагасы болынлыкка төштеләр (Г.Гобәй); ә) тәмамлык: Әллә нинди шунда эчтәге бөтен нәрсәне бик төптән кузгата торган, бер үк вакытта бөтен җан иясен – адәмнәрне, кошларны, чәчәкләрне, бөҗәкләрне әрнеп кызганырга һәм өзелеп сөяргә мәҗбүр итә торган көй иде шул бу дәдәм көе! (Ә.Еники).

Гомуми мәгънәле сүз белән тиңдәш кисәкләр үзара бер грамматик формада ярашалар. Бу да аларны

аныкланмыш белән аныклагыч итеп карарга этәргеч бирә. Мәсәлән, аныкланмыш урын хәле вазифасын башкарса, алар урын-ара килеше формаларында үзара ярашалар: Биредә дөньяның төрле почмакларыннан – Һиндстаннан, Кытайдан, Япониядән, Австралиядән, Африкадан. Америкадан китерелгән бик күп төрле гаҗәеп агачлар үсеп утыралар (Ә.Еники).

Димәк, алда карап кителгән очракларның барысын да аныклаулы мөнәсәбәт нәтиҗәсе итеп карарга җирлек бар.

Татар һәм башка төрки телләрнең синтаксисларында, гомумиләштерүче сүзләр итеп, билгеләү һәм юклык алмашлыклары гына алына. Ләкин безнең күзәтүләр болардан башка бик күп төрле сүз төркемнәре, аларның формалары һәм сүзтезмәләр белән бирелүен күрсәтә:

а) Күрсәтү алмашлыгы белән: Тегеләр – Мөнәвәрә белән Сәхибә, күрәсең, бу хәлләр турында инде хәбәрдар иде, җырлый-җырлый шәл бәйләделәр, Асаф тыңлады да тыңлады (М.Мәһдиев).

б) Зат алмашлыгы белән: Беләсең килсә, без инде күптән балаларча уйламыйбыз: син дә, мин дә, бүтәннәр дә (Ф.Яруллин).

в) Билгесезлек алмашлыгы: Утызынчы елның январь ахырында Поник мәктәбенең ике укытучысы әллә кайларга – *волостьларга, кантонга, шәһәргә* йөреп ниндидер хикмәтле шартлаткыч алып кайттылар да чиркәү гөмбәзен шартлатырга җыендылар (М.Мәһдиев).

Күплек сандагы, яисә җыелма төшенчәле исем һәм исем урыныда килә торган башка сүзләр белән дә бирелә ала.

а) Исем сүз төркеме белән бирелгән гомумиләштерүче сүзләргә мисаллар: Клубны селкетеп кул чаптылар, сәхнә янындагы кешеләр – укытучылар, укучылар аны кочактан-кочакка йөрттеләр (М.Мәһдиев).

б) Аныкланмышлар исемләшкән башка сүз төркемнәре белән дә белдерелә ала: Монда синдәйләр аралаша: соры шинельле солдатлар, офицерлар, һава көчләре, десант, танк, элемтә, эчке эшләр, чик буе гаскәрләре малайлары (М.Мәһдиев).

Шулай ук гомумиләштерүче сүзләр бер сүз белән генә түгел, ә төрле сүзтезмәләр белән дә бирелә ала: а) Исемле исем сүзтезмәләр белән бирелгән гомумиләштерүче сүзләр кергән җөмләләр: Бүрек белән киңәшеп, башны кашып торгач, Туган ягы Актаныш авылларыннан*: Иске Кормаштан, Җияштән, Каентүбәдән* грузчиклар әртиле оештырды (Г.Ахунов).

б) Сыйфатлы исем сүзтезмәләрдән торган гомумиләштерүче сүзләр: Монда торганы яфраклы агач иде: каен, юкә, усак, чаган, карама, элмә – танып бетермәссең, ләкин бер генә дә ылыслы агач юк (Ә.Еники).

в) Алмашлыклы исем сүзтезмәләрдән торган гомумиләштерүче сүзләр: Аңа телем дә, Аппак та аз иде, аңа Алмаш ханның бөтен байлыгы – җире-суы, иле-көне кирәк иде (Н.Фәттах).

г) Шулай ук гомумиләштерүче сүзе рәвешле исем сүзтезмәләр белән белдерелгән җөмләләр дә еш очрый: Кешелек җәмгыяте капчыктан өстен булырга тырышып күп әйбер уйлап тапты: саквояж, ранец, чемодан, ридикюль, планшетка, рюкзак, дипломат һәм тагын әллә ниләр (М.Мәһдиев).

д) санлы исем сүзтезмәләр гомумиләштерә: Син ике ут арасында калгансың. Дөресе, өч ут: ике үги ана, бер үги ата (Ә.Баянов)

е) алмашлыклы алмашлык сүзтезмәләр белән: Бу кыз үзенең бөтен барлыгы – яшьлеген, пакълеген, саф хисләрен, күбәләк канатыдай җилфердәп торган күңелен, яшь болан баласыдай ыргым, саглам гәүдәсен менә шушы мизгел өчен саклап алып килде – бу татлы төшне аннан кызганмагыз (М.Мәһдиев).

г) Модаль сүзле алмашлык сүзтезмәләр белән: Десантниклар өчен иң кирәк нәрсә: физик көч, теләсә нинди шартларда да югалып калмау, тиз ориентлаша белү һәм рухи яктан нык булу (Ә.Баянов).

Алдагы мисаллардан күренгәнчә, гомумиләштерүне билгеләү һәм юклык алмашлыклары гына түгел, башка сүз төркемнәре белән дә, мәсәлән, күрсәтү, зат, сорау, билгесезлек алмашлыклары, исемнәр һәм исемләшкән башка сүзләр, моннан тыш, алмашлыклы алмашлык, исемле исем, сыйфатлы исем, алмашлыклы исем, рәвешле исем, санлы исем һ.б. бик күп төрле сүзтезмәләр дә белдерә ала. Димәк, болар бар да аныклаулы мөнәсәбәт нәтиҗәсе булып тора. Шулай булгач, синтаксиста традицион рәвештә гомумиләштерүче сүз итеп карала торган барлык һәм юклык алмашлыкларын аерым алып карауның кирәге калмый. Тиңдәш кисәкләр шул ук аныклагычлар, ә "гомумиләштерүче сүзләр" аныкланмышлар алар. Тиңдәш кисәкләр бу очракта аныклагычларның бирелү ысулы гына. Аныклагычлар, димәк, бер генә сүз белән дә, сүзтезмәләр һәм тиңдәш кисәкләр белән дә бирелергә мөмкин. Шуңа күрә гомумиләштерүче сүзләрне һәм тиңдәш кисәкләрне аерым алып өйрәнүнең кирәге бөтенләй калмый. Алар аныклагычлар темасында үтелергә тиеш. Димәк, тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр бер үк синтаксик вазифа башкаралар дигән традицион караш дөрес булып чыкмый.

Әлеге синтаксик категорияләрне грамматик, логик һәм семантик яктан карап, шундый нәтиҗәләргә килергә мөмкин: тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр төрле җөмлә кисәге вазифасын башкаралар. Алда килгән гомумиләштерүче сүзләр тиңдәш кисәкләр белән аныклаулы мөнәсәбәттә булалар, алар үзара аналитик чара (аныклау интонациясе) белән бәйләнәләр. Аныкланмыш теләсә нинди җөмлә кисәге (ия, тәмамлык, аергыч, хәбәр һ.б.) була, ә тиңдәш кисәкләр бары тик аныклагыч вазифасын гына башкаралар.

**Әдәбият**

1. Галләмов Ф.Г. Тиңдәш кисәкләрнең һәм гомумиләштерүче сүзләрнең синтаксик вазифалары // Милли

мәдәният. – 2003. – №4. – Б. 41–46.
2. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле синтаксис һәм пунктуациясе. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1984. – 258 б.
3. Мифтахов Б.М. Татар теле. 6 кл. өчен дәреслек. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981. – 136 б.
4. Мифтахов Б.М. Татар теле синтаксисын укыту методикасы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1968. – 136 б.
5. Сайкин Ш. Синтаксик төзелмәләрнең аерымлануы, аның кыен очраклары. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1980. – 160 б.
6. Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы: Морфология һәм синтаксис. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1959. – 642 б.

**Гарипова Айзирә Шамил кызы,**

**Устимова Гөлчәчәк Шамил кызы,**

**Абдуллина Гөлнара Вәзир кызы,**

*МАББУ «17нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*
*Әлмәт шәһәре, Татарстан, Россия*
*e-mail: 9172902183@mail.ru, aisira.79@mail.ru*
*aisira.79@mail.ru, ustimova_1971@mail.ru*

УДК 81.373

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КУШЫМЧАЛАР ЯРДӘМЕНДӘ ИСЕМ ҺӘМ СЫЙФАТ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕННӘН БУЛГАН ТЕРМИННАР ЯСАЛЫШЫ

# ОБРАЗОВАНИЕ ТЕРМИНОВ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

# FORMATION OF TERMS IN TATAR LANGUAGE

**Аннотация.** В последние два десятка лет происходит интенсивный рост количества новых татарских терминов и понятий, используемых в различных областях. Это вполне объяснимое явление, связанное с преподаванием предметов на татарском языке, с активной издательской деятельностью, ведением делопроизводства, Интернет- сайтов на татарском языке и, что особенно важно, принятием Закона РТ «О языках народов РТ», согласно которому татарский язык является одним из государственных языков в Республике Татарстан.

**Ключевые слова:** терминология,тюркология, грамматика.

**Abstract.**For the last two decades the intensive growth of the number of new Tatar terms and definitions has been happening, being used in the various fields.This is understandable phenomenon associated with teaching subjects on Tatar language, with an active publishing, records management, Internet sites on the Tatar language, and most importantly is the adoption Law of the Tatarstan Republic "About languages of the Tatarstan Republic", according to which the Tatar language is the one of the official languages of the Tatarstan Republic.

**Keywords:** terminology, turkology, grammar.

Татар әдәби теленең бай тарихы булган, заманында кызу бәхәсләр кузгаткан, төрле агымнар арасында үзенчәлекле көрәш тудырган, кызыклы һәм катлаулы проблемаларның берсе – терминология. Билгеле ки, телебездә атамалар төзү революциягә кадәр үк яктыртыла килгән, тик алар һәркайсы үз чорының берәр яклы карашын, вакыт-вакыт сыйнфый яки субъектив тарафчылык йогынтысын чагылдырганнар. 1930-1940 нчы елларда теориягә караганда практикачылык өстенлек итә. 1950-1960 нчы елларда фәнни теория һәм методлар нигезендә тикшерү шартлары туган. Әлбәттә, терминология мәсьәләсе фән-техниканың эше генә түгел. Ул мәктәп эшчәнлеге белән дә турыдан-туры бәйләнгән. Шуңа күрә бүгенге көндә дә терминнар киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә.

Сүзьясалыш ысуллары

Сүзьясалыш ысулы – нинди дә булса телнең материаль берәмлекләреннән, алар арасында сүзьясалыш мөнәсәбәтләре хасил итеп, яңа сүзләр ясау алымы, методы. Татар тел белемендә сүзьясалыш хакында бик үк